**УДК 070**

*Фәнни редактор*
филология фәннәре докторы, проф. В.З.Гарифуллин

*Рецензентлар:*
филология фәннәре кандидаты Сабирова Л.Р.
филология фәннәре кандидаты Галиәхмәтова А.Ф.

**Зәйни Р.Л.**
**Журналистның һөнәри этикасы (программа, методик күрсәтмәләр, лекцияләр):** Укыту-методик кулланмасы / Р.Л.Зәйни. – Казан: Казан университеты, 2013. – 38 б.

Әлеге кулланма “Журналистның һөнәри этикасы” дисциплинасын үзләштерүче студентларга адреслана.

Пособие адресовано студентам, изучающим дисциплину “Профессиональная этика журналиста».

© Казанский университет, 2013
© ЗАЙНИ Р.Л., 2013

## Эчтәлек

**Кереш ........................................................................................ 4**
**Курсның төп бүлекләре ................................................................... 5**
**Аудитор һәм аннан тыш эшчәнлекне оештыру чаралары .................. 8**
Контроль эшләр өчен сораулар ..............................................................8
Семинар дәресләрнең темалары ........................................................... 9
Рефератлар һәм докладлар өчен темалар .................................................. 10
Курсны үзләштерү барышында кулланылырга мөмкин булган әдәбият .. 11
Зачет өчен сораулар .............................................................……… 13
**Лекцияләр һәм үзлектән әзерләнү өчен материаллар …..………….. 15**
Гомуми һөнәри этика ……………………………………………..……..15
Журналист һөнәре этикасы ………………………………………………..22
Россия журналистының һөнәри этика кодексы .................................... 36

# Кереш

Кемне һөнәрмәнд, профессионал дигән зур исем белән атап йөртәләр? Әлбәттә, үз һөнәренең барлык нечкәлекләрен белеп бетергән кешене. Журналистика турында сүз алып барганда, тормыш тәҗрибәсе туплаган, теоретик яктан һөнәри әзерлек алган һәм, әлбәттә, җәмгыять куйган әхлакый таләпләргә хыянәт итми яшәргә һәм эшләргә тырышкан кеше турында гына шулай дип әйтелергә тиешлеге бәхәссез. Бу очракта әхлакый таләпләрдән бер адым да читкә тайпылмый яшәргә һәм эшләргә тиеш, дигән шарт та куярга мөмкиндер бәлки. Әмма тормышта гел алай гына булып бетми: бүгенге җәмгыятьтә абсолют һәм идеаль һөнәри әхлакка ирешү мөмкин дә түгел. Әмма аңа омтылырга кирәк. Шулай булгач, профессионаллар турында сүз алып барганда, шул әхлакка ирешергә тырышкан кешеләр дип атасак, дөресрәк булыр, мөгаен.

Әлеге курсның максаты - студентларда һөнәри этика өлкәсендә белем һәм күнекмәләр формалаштыру, ягъни һөнәри әзерлек баскычларының бер таләбен үзләштерү.

Һөнәри этика дигәндә, һөнәри эшчәнлек барышында журналист тарафыннан кулланыла торган тәртипкә салучы, көйләүче чаралар исемлегенә кергән кыйммәтләр, таләп һәм кагыйдәләр күз алдында тотыла.

Максатны тормышка ашыру барышында Көнбатыш Европа, АКШ һәм Россия журналистларының һөнәри этикасы барлыкка килү һәм үсеше тарихын, журналистлар тарафыннан этик стандартларның үтәлешен тикшереп торучы җәмгыять контроле чараларын, катлаулы ситуацияләрдән чыгу өчен башкарыла торган адымнарга этик анализ алымнарын өйрәнү, төрле журналист системаларындагы этик таләпләрне чагыштыру, һөнәри этиканың әһәмияте һәм урыны турында фикерләшү планлаштырыла.

Студентлар курсны үзләштерү ахырында Россия һәм халыкара этика нормаларын, кодексларын белергә, аларның әһәмиятен аңларга, көндәлек эшчәнлек барышында аларны гамәлдә кулланып, хезмәттәшләренең адымнарын этик яктан анализлый белергә тиеш.

Әлеге дисциплина бакалаврлар әзерләү барышында 3 нче курста (5 нче семестр) өйрәнелә һәм «Һөнәри дисциплиналар циклы»на кертелгән, уку планында Б3. Б.16 шифры белән бирелә. Аңа барысы 3 зачет берәмлеге һәм 108 сәгать (16 сәгать лекция, 16 сәгать практик дәресләр, 76 сәгать мөстәкыйль эш) каралган. Курс зачет белән тәгәлләнә.

# Курсның төп бүлекләре

**1 нче тема. Әхлак һәм җәмгыять. Һөнәри этика**

Иҗтимагый аң формасы, кешенең башкаларга мөнәсәбәтен һәм җәмгыятьтә яшәү рәвешен билгеләүче нормалар системасы буларак әхлак. Әхлакның җәмгыять тормышында үтәгән бурычлары: билгеле бер социаль системаның яшәешен тәэмин итү, җәмгыятьтә төрле төркем һәм индивидларның үзара тәэсир итешүләрен тәртипкә салу, шул җәмгыятьтә кабул ителгән үз-үзеңне тоту һәм эшчәнлек кагыйдәләрен үтәтү, теләсә кайсы эшчәнлек төренә карата бәя бирүче ролен башкару.

Әхлакый нормаларның барлыкка килү сәбәпләре һәм механизмы (ситуация – бәяләү – эш-хәрәкәт – нәтиҗә), максатлары һәм эчтәлеге. Әхлакый нормаларның тарихи чорлар дәвамында барлыкка килгән төрләре: дворянинның намус кодексы, мещан әхлагы, табиб этикасы һ.б. Мәҗбүри, рөхсәт ителгән, бәхәсле әхлак нормалары.

**2 нче тема. Әхлак нормаларының журналистикада тоткан урыны**

Журналистларның һөнәри әхлак кагыйдәләренең барлыкка килү алшартлары. Журналистның социаль һәм һөнәри бурычларын башкару барышында, һөнәри этиканың көйләүче, тәртипкә салучы ролен үтәве.

Аерым һөнәр иясе һәм бер илнең гражданы буларак, төрле әхлак кагыйдәләренең бер кешедә беренчелек өчен көрәше. Тормыш позициясе һәм авторлык позициясе. Журналистиканың роле һәм бурычлары.

Россия журналистларының һөнәри этикасы, аларның гамәлгә кертә бару тарихы. Журналист әхлагы нормаларының һөнәргә бәйле үзенчәлекләре, башка һөнәрләрнең этика кагыйдәләре белән бәйле охшаш һәм аермалы яклары.

Үзара тәртипкә салу механизмы буларак этика кодексы, декларация, хартияләр. Журналистларның үз-үзләрен тоту принципларының халыкара декларациясе. Аның төп моментлары. Россия журналистларының һөнәри этика кодексы. Аның барлыкка килү тарихы. Кодекстагы уңышлы һәм җитешсез яклар. Иҗади төркемнәр яки аерым коллективлар кабул иткән әхлакый кодекслар. Россия теле-, радиожурналистлары хартиясе, Россия суд репортерлары гильдиясе декларациясе. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары кабул иткән кодекслар. Журналистика этикасының халыкара принциплары.

**3 нче тема. Социаль җаваплылык - әхлакый категория**

Журналистикада социаль җаваплылык төшенчәсе. Аның журналист эшчәнлегендәге эчке мәгънәсе, эчтәлеге. Дәүләткә, җәмгыятькә, милләткә, халык төркемнәренә, аерым бер шәхескә карата мөнәсәбәт.

Иҗади шәхес буларак, журналистка эш барышында төрле факторларның тәэсир итүе, басым ясавы (баш мөхәррир авторитеты, гореф-гадәтләр, традицияләр, «көтү» психологиясе). Фактларны хис-тойгылардан һәм шәхси фикерләрдән аерып бирүдән гыйбарәт булган объективлык.

Массакүләм мәгълүмат чараларын референт төркем буларак сыйфатлау. Журналистикада теге яки бу предмет, күренеш, шәхескә карашын белдерү максатыннан кулланыла торган психологик алымнар һәм чаралар. Тәкъдим ителә торган мәгълүматны кабул итәргә этәрү ысулы. Журналистның үз фикерен укучы, тыңлаучы, тамашачыга көчләп тагу очраклары.

Конкрет материалны әзерләгәндә, журналистның алдына үзмаксат куюы. Һөнәри җаваплылык. Кешеләр язмышы белән уйнамау, журналист авызыннан чыккан һәр сүзнең нинди нәтиҗәгә китерәчәген алдан күреп эш итү. Хезмәт урынын башкаларга янау, үч алу өчен кулланмау. Мәгълүмат алу өчен генә кешеләрне алдамау. Фактларны үзгәртү, дөреслекне «матурлап җибәрү» ялгышлары.

Репортер әхлагы объекты буларак, мәгълүмат чыганаклары. Мәгълүмат чыганакларына мөмкин кадәр азрак зыян салу принцибы. Мәгълүмат чыганакларын һөнәри этика нормалары күзлегеннән чыгып төркемнәргә берләштерү. Рәсми һәм рәсми булмаган чыганаклар. Шәхси, коллектив һәм документаль чыганаклар белән эшләү үзенчәлекләре.

Мәгълүмат җыюның рөхсәт ителгән һәм тыелган ысуллары. Әңгәмә уздыру этикасы. «Һөнәр алыштыру», «ялган танышу» алымнарын куллануга карата мөнәсәбәт. Эксперимент шартларында күзәтүләр алып барганда әхлакый чикләүләр. Диктофон, «яшерен камера» куллану, алар ярдәмендә табылган мәгълүматны эфирга яки матбугатка чыгаруның этик аспекты.

**4 нче тема. Бүгенге көндә һөнәри этика проблемалары**

Журналистиканың бәйсезлеге проблемасы. Дәүләт һәм журналистика, массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә куючылар һәм журналистлар, мәгълүмати эшчәнлекнең башка субъектлары арасындагы мөнәсәбәтләрнең хокукый яктан көйләнгән булуы.

Җәмгыятьтә икътисадый, социаль һәм сәяси фикер төрлелегенең

журналистиканы объектив итүгә ясаган тәэсире.

Россиядә барган иҗтимагый процессларның нәтиҗәсе буларак, журналистикада бүген урын алган әхлакый ситуация.

Журналистиканы идеологик нигездә көйләп торган элеккеге кыйммәтләр һәм нормалар системасының җимерелүе. Массакүләм «сары матбугат» барлыкка килү һәм аңа гына хас булган һөнәри этика кодексының гамәлгә керүе. Әлеге кагыйдәләрнең гомумжурналистикада таралуы.

Журналистикада хәбәрдарлыкның чикләре. Табу (тыелган) темалар. Массакүләм мәгълүмат чараларын цензура астына алуның уңай һәм тискәре яклары.

Материал героеның, персонажның эчке тормышына һәм дөньясына «бәреп керүнең» чикләре.

Бүгенге җәмгыятьтә, массакүләм мәгълүмат чаралары базарында скандаллар һәм популярлык. Расланмаган, дәлилләнмәгән мәгълүматларны тикшермичә генә аудиториягә ирештерү проблемасы.

«Заказ буенча» материаллар әзерләү. «Яшерен реклама» һәм рухи кыйммәтләр нормаларының үзара кисешүе.

Редакция коллективы һәм хезмәт урыны этикасы кагыйдәләре. Журналистлар бергәлеге: чынбарлык яки уйдырмамы? Журналистлар арасында көндәшлек. Карьера, танылуга омтылу шартларында үзара этика нормаларын үтәү. Һөнәргә тап төшермәү мәсьәләсе. Плагиат. «Ачык чыганаклар»дан файдаланганда, авторлык хокукларын саклау проблемасы.

Журналист һәм хакимият органнары арасындагы этик чикләр. Сайлау алды компанияләрен яктыртуга әхлакый караш. Журналист һөнәренең сәясәт өлкәсе белән кисешү нокталары.

**5 нче тема. Журналист тексты – һөнәри этика объекты.**

Журналист өчен текст төзү вакытында үтәлергә тиешле таләпләр:

•Чынбарлыкны өйрәнү вакытында табылган барлык мәгълүмат, фикер, бәя бирүләрнең барысын да исәпкә алу, берсен дә төшереп калдырмау.

•Күренеш яки проблема турындагы төрле карашларны, фикер каршылыгын бирү.

•Фактлар турында хәбәр иткәндә, материалда башка кешеләрнең фикерләрен китергәндә, журналистның нейтраль мөнәсәбәт саклавы.

•Үз фикерләрен һәм бәясен биргән очракта, журналистның аларны дәлилләве.

# Аудитор һәм аннан тыш эшчәнлекне оештыру чаралары

Уку барышында семинар дәресләр, реферат яклаулар, докладлар һәм контроль эшләр уздырыла.

***Контроль эш*** семестрда ике тапкыр үткәрелә һәм 40 минут дәвам итә. Студентларга сораулар бирелә, алар җавапларны язма рәвештә укытучыга тапшырал. Бәя алдагы дәрес барышында игълан ителә, хаталар күрсәтелә.

## Контроль эшләр өчен сораулар

**Беренче контроль эш**

1. Әхлак нормаларының журналистикада тоткан урыны.
2. Журналистларның һөнәри этика кагыйдәләренең барлыкка килү алшартлары.
3. Россия журналистларының һөнәри этикасы, аларның гамәлгә керә бару тарихы.
4. Үзара тәртипкә салу механизмы буларак этика кодексы, декларация, хартияләр.
5. Журналистика этикасының халыкара принциплары.

**Икенче контроль эш**

1. Журналист өчен текст төзү вакытында үтәлергә тиешле таләпләр.
2. Әлеге таләпләрне үтәү шартлары.
3. Журналист һәм хакимият арасындагы һөнәри әхлак мөнәсәбәтләре.
4. Журналист һәм мәгълүмат адресаты (аудитория) арасындагы һөнәри әхлакый мөнәсәбәтләрен билгеләүче нормалар.
5. «Автор» төшенчәсе. Журналист һәм автор арасындагы мөнәсәбәтләр.

***Семинар дәресләр*** аерым темага багышлана. Аның темасы һәм сораулары алдан ук игълан ителә, студентлар дәрескә кадәр аларга махсус әдәбият ярдәмендә әзерлек алып бара. Дәрес вакытында сорауларга җавап үзара сөйләшү, фикер алышу, бәхәс формасында алып барыла.

## Семинар дәресләрнең темалары

**1 нче тема. Һөнәри этика фән буларак**

1) Җәмгыятьтәге әхлакый мөнәсәбәтләр. Һөнәри этика.

2) «Этика» төшенчәсе. «Әхлак» һәм «этика» төшенчәләре арасындагы элемтә һәм аерымлык.

3) Һөнәри этиканың төп принциплары.

**2 нче тема. Һөнәри этиканың журналист эшчәнлегендә тоткан урыны**

1) Россия журналистлар корпусында һөнәри әхлакның эшләү механизмы.

2) «Принцип» төшенчәсе. Журналист эшчәнлегенең һөнәри әхлак принциплары.

3) «Принцип» һәм «норма». Журналист эшчәнлегендәге төп һөнәри әхлак норма төркемнәре.

**3 тема. Социаль җаваплылык – әхлакый категория**

1) Һөнәри позиция, аның кешенең тормыш позициясеннән аерылып торуы.

2) Һөнәри бурыч. Аны үтәү-үтәмәү нәрсәгә бәйле? Ул һәрвакытта да үтәлергә тиешме?

3) «Һөнәри җаваплылык» һәм «һөнәри намус» төшенчәләре арасындагы уртак һәм аерым сыйфатлар.

**4 тема. Бүгенге көн журналистикасындагы һөнәри этика проблемалары**

1) Геройларның яки мәгълүмат чыганакларының аноним булып калу теләгенә бәйле һөнәри проблемалар. Мәгълүматның конфиденциальлеге, мәгълүмат чыганагы яки журналистның анонимлык мәсьәләсе.

2) Мәгълүмат чыганагы һәм журналист арасындагы үзара килешү мөмкинлекләре.

3) Яшерен аудио- яки видеоязма алып бару, «куркыту», «маска», «һөнәр алыштыру» чараларын куллануга этик караш.

**5 тема. Журналист тексты – һөнәри этика объекты**

1) Журналист һәм мәгълүмат чыганагы арасындагы әхлакый мөнәсәбәтләрне тәртипкә салучы нормалар.

2) Журналист һәм язма геройлары арасындагы әхлакый мөнәсәбәтләрне тәртипкә салучы нормалар.

3) «Һөнәри этика» һәм «хезмәт этикасы» төшенчәләре арасындагы уртаклыклар. Редакциядәге әхлакый климат.

## Рефератлар һәм докладлар өчен темалар

1. Журналистларның үз «Гиппократ анты» була аламы?
2. Журналист. Тәнкыйть күзлегеннән бер караш.
3. Журналистны һөнәри этика кагыйдәләренә кем өйрәтер?
4. Этика һәм бизнес.
5. Карьера һәм этика.
6. Сайлаулар вакытында журналист кем ягында булырга тиеш?
7. Интернет һәм журналист этикасы.
8. Папарацци һәм һөнәри этика.
9. Яшерен реклама һәм журналист этикасы.
10. Журналист геройларының шәхси тормышын фаш итәргә хаклымы?
11. Җинаять корбаннары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары.
12. Атаклы кешеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары арасындагы кискен мөнәсәбәтләр.
13. Укучы алдында җаваплылык хисе.
14. Сүз кешене үтерә дә, терелтә дә...
15. Мәгълүмат чыганагын сер итеп саклау таләбенең үтәлеше.
16. Һөнәри этика кодекслары: охшаш һәм аерымлы яклары.
17. Газета (журнал, радио-, телеканал) ялган мәгълүмат таратты. Хатаны ничек төзәтергә?
18. Тәҗрибә һөнәри этикага өйрәтәме?
19. «Һөнәр алмашу» ысулының һөнәри этикага ни катнашы бар?
20. Диктофон куллану һәрвакытта да әхлакка туры киләме?
21. Үз хаталарыңны тану һәрвакытта да кыен.
22. Сенсация артыннан куунның уңай һәм тискәре яклары.
23. Тәрҗемәче һәм авторлык мәсьәләсе.

## Курсны үзләштерү барышында кулланылырга мөмкин булган әдәбият


***Төп әдәбият***

Авраамов, Дмитрий Сергеевич. Профессиональная этика журналиста: учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по направлению и спец. «Журналистика» / Д. С. Авраамов.-[2-е изд., испр. и доп.].-Москва: Изд-во Моск. ун-та, 2003.-271 с.; 22.-На 4-й с. обл. авт.: Д.С. Авраамов, д.филос.н., проф., засл. работник культуры РФ.-Библиогр. в подстроч. примеч..-ISBN 5-211-04706-0, 3000.

Лазутина, Галина Викторовна. Профессиональная этика журналиста: учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по спец. «Журналистика» / Г.В. Лазутина.-2-е изд., перераб. и доп..-Москва: Аспект Пресс, 2006.-239, [1] с.: схемы; 22.-Библиогр. в примеч.: с. 200-208 и на с. 238.-ISBN 5-7567-0384-5, 3000.

***Өстәмә әдәбият***

Ворошилов, Валентин Васильевич. Журналистика: учебник для студентов высших учебных заведений, обучающихся по гуманитарным специальностям / В. В. Ворошилов; Санкт-Петербургский гос. ун-т сервиса и экономики.—6-е изд., перераб. и доп..—Москва: КноРус, 2009.—491 с.: табл.; 25 .—Библиогр.: с. 486-491 (139 назв) и в конце гл..—ISBN 978-5-390-00149-3((в пер.)), 3000.

Гусейнов А.А. Этика и мораль в современном мире / Гусейнов А.А. // Вестник МГУ. Сер.7, Философия.—Б.м...—2001.—N1.—С.18-26.—ISSN 0130-0091.

Гусейнов, Абдусалам Абдулкеримович. Этика: учеб. для студентов вузов / А. А. Гусейнов, Р. Г. Апресян.—М.: Гардарики, 2004.—470с..—(Disciplinae).—Библиогр. в конце тем.—Имен. указ.: с.461-464.—ISBN 5-8297-0012-3((в пер.)).

Де Джордж, Ричард Т. Деловая этика: Учеб. курс для колледжей и ун-тов / Ричард Т. Де Джордж; [Пер. с англ. Р.И. Столпера].—М.: РИПОЛ КЛАССИК: Прогресс, 2003.—733, [1] с.; 25.—Загл. и авт. ориг.: Business ethics / Richard T. De George.—Библиогр. в подстроч. примеч..—Указ.: с. 711-727.—ISBN 5-7905-1782-X((РИПОЛ КЛАССИК)).—ISBN 5-01-004741-1((Прогресс)), 5000.—ISBN 0-13-079772-3((США)), 5000.

Корконосенко, Сергей Григорьевич. Основы журналистики: учебник для студентов вузов, обучающихся по направлению и специальности «Журналистика» / С. Г. Корконосенко.—М.: Аспект-Пресс, 2004.—285, [1] с..—Библиогр.: с. 284-285.—ISBN 5-7567-0158-3.

Муратов, Сергей Александрович. ТВ-эволюция нетерпимости (история и конфликты этических представлений) / Сергей Муратов.—М.: Логос, 2001.—239с..—ISBN 5-94010-028-7: 58.50.

Основы этических знаний: Учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по филос. спец. / В.П. Клычков, М.Н. Росенко, А.М. Склярова и др.; Отв. ред. М.Н. Росенко.-2-е изд., испр. и доп..-СПб.: Лань, 2002.-223с..-ISBN 5-8114-0397-6.

Прохоров, Евгений Павлович. Введение в теорию журналистики: учебник для студентов высших учебных заведений, обучающихся по направлению 520600 и специальности 021400 «Журналистика» / Е.П. Прохоров.—8-е изд., испр..—Москва: Аспект Пресс, 2012.—349, [1] с.; 22.—ISBN 978-5-7567-0615-4((в пер.)), 1500.

Разин, Александр Владимирович. Этика: Учеб. для студентов филос. специальностей / А.В. Разин; Моск. гос. ун-т.—М.: Акад. Проект, 2003.—621, [1]с..—(Gaudeamus).—ISBN 5-8291-0284-6.

Рих, Артур. Хозяйственная этика / Артур Рих; отв. ред., авт. вступ. ст. и коммент. В. В. Сапов; пер. с нем. Е. М. Довгань.—Москва: Посев, 1996.—809, [1] с.: портр.; 21.—Библиогр.: с. 691-752 (651 назв.) и в коммент.: с. 754-784.—Указ. имен: с. 786-802, 5000.

Шайхитдинова, Светлана Каимовна. «Натуралистические сюжеты» криминальной хроники и профессиональная этика журналиста / С. К. Шайхитдинова // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы VIII Междунар. науч.-практ. конф. / науч. ред. В.З. Гарифуллин; авт.-сост. Р. П. Баканов.—С. 412-416.—Казань, 2011.

***Интернет ресурслары***

Общественная коллегия по жалобам на прессу // http://www.presscouncil.ru/

Право и Интернет // http://www.russianlaw.net/law/

Союз журналистов России // http://www.ruj.ru

Библиотека Центра экстремальной журналистики // http://www.library.cjes.ru

***Кодекслар һәм норматив документлар***

Международная Федерация журналистов. Декларация принципов поведения журналистов // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_01

Общество профессиональных журналистов. Кодекс этических норм // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_02

Союз журналистов России. Кодекс профессиональной этики российского журналиста // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_03

Московская Хартия журналистов. Декларация // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_04

Хартия телерадиовещателей // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_05

Положение о принципах и системе общественного контроля за соблюдением журналистами положений Кодекса профессиональной этики российского журналиста // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_06

Положение о Большом Жюри СЖР // http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#з_07

## Зачет өчен сораулар

1. Нәрсә ул һөнәри этика?
2. Журналистларның һөнәри этикасы барлыкка килү.
3. Безнең илдә журналистиканың һөнәри этика тарихы.
4. Россия журналистларының һөнәри этика кодексы: уңай һәм тискәре яклары.
5. Чит ил массакүләм мәгълүмат чараларының һөнәри этикасы.
6. Журналист этикасының халыкара принциплары.
7. Мәгълүмат чыганаклары – репортерның әхлакый мөнәсәбәтләр объекты.
8. Мәгълүмат чыганагын һөнәри этика күзлегеннән чыгып төркемләү.
9. Мәгълүмат чыганагына акча түләү мәсьәләсе.
10. Әңгәмә алып бару этикасы. Төп таләпләр.
11. «Һөнәр алмашу» ысулын куллануның этик чикләре.
12. Мәгълүмат алуның рөхсәт ителгән һәм тыелган алымнары.

13. Эксперимент шартларында журналист күзәтүләре. Әхлакый тыюлар.

14. Диктофон, «яшерен камера» куллану, видеоматериалны халыкка чыгаруның этик аспекты.

15. Журналист-укучы мөнәсәбәтләренең әхлакый үзенчәлекләре.

16. Хәбәрдарлыкның чикләре буламы?

17. Журналист өчен серләр яки табу төшенчәсе.

18. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм цензура.

19. Объективлыкка ирешү юллары.

20. Укучыга тәэсир итәрлек психологик чаралар.

21. «Яшерен реклам» әзерләгәндә килеп туган әхлакый проблемалар.

22. Хезмәтебез өчен яшерен бүләкләр кабул итәргә хокукыбыз бармы?

23. Заказга эшләргә ярыймы?

24. Журналист һәм материал герое арасындагы мөнәсәбәтләрнең әхлакый ягы.

25. Персонажларга зыян китермәү принцибы.

26. Журналист өчен үз героеның эчке дөньясына һәм шәхси тормышына бәреп керү хокукы.

27. Җинаятьләр, террорчылык актларын яктыртуга әхлакый якын килү.

28. Редакция коллективы һәм хезмәт этикасы нормалары.

29. Журналистлар бергәлеге: уйдырма яки чынбарлык?

30. Сайлау алды компаниясен яктырту вакытында әхлакый мөнәсәбәтләр.

31. Массакүләм мәгълүмат чараларының икътисадый проблемалары һәм журналист һөнәренә этик караш.

32. «Дүртенче хакимият»не кем һәм нәрсә өчен тәнкыйтьли?

33. Сүз һәм массакүләм мәгълүмат чаралары иреге.

# Лекцияләр һәм үзлектән әзерләнү өчен материаллар

## Гомуми һөнәри этика

***Һөнәри әхлак.*** Әхлакый нормаларның кешегә юнәлдерелгән, аның тормышын, сәламәтлеген, иреген яклауга багышланган принциплары гасырлар буе формалашкан. Әгәр дә инде шул гомуми әхлакны нинди дә булса аерым бер һөнәр кысаларында гына карасак, ул нормаларны без һөнәри әхлак дип атар идек. Ягъни алар кеше башкарган хезмәт үзенчәлекләренә бәйле була. Җәмгыятьтә бер төрлерәк функция башкаручылар аларга гына хас булган аерым әхлак нормаларын барлыкка китерә. Бу нормалар һөнәри бурычларны нәтиҗәлерәк үтәргә ярдәм итә һәм шәхеснең, җәмгыятьнең үсешенә китерә.

Һөнәри әхлак нормаларын һөнәри этика өйрәнә. Һөнәри этика һәр һөнәри төркем вәкилләренең эш барышында барысыннан да еш кулланган таләпләре нигезендә формалашкан. Бу таләпләр язылган һәм язылмаган кануннар формасында төрле этика кодексларында чагылыш таба. Нәкъ менә шул кодекслар һөнәри этиканы фән югарылыгына күтәрүче беренче адымнар була да инде.

Шуны аерым әйтеп китү кирәк: файдалы хезмәт кешегә йөз белән борылган, аның тормышын яхшырту өчен башкарыла, димәк, аның нигезендә гуманлылык принцибы ята.

Һөнәр (латинчадан professio, profiteor – үз эшем итеп игълан итәм дигәнне аңлата) – рәсми яктан күрсәтелгән эш төре. Ә менә белгечлек (латинчадан species – төр) бер һөнәр кысаларында махсус назәри һәм гамәли әзерлекле, аерым тәҗрибәгә ия кешенең эшчәнлек төре. Мисалга, без табиплар арасында күз табибы, кардиолог, балалар табибы, хирург кебек белгечлекләрне аерып күрсәтә алабыз.

Һөнәр атамасы шул эшнең эчтәлеге һәм бурычларыннан, эш коралларыннан чыгып атала. Җәмгыятьтә җитештерүче көчләр үсеш кичерә барган саен, яңа эш кораллары, технологик чаралар, җитештерү төрләре һәм фән өлкәләре барлыкка килгән, шулар белән бергә хезмәт бүленеше дә тирәнәя барган. Һөнәр үзләштерү гомуми һәм махсус белемнәрне өйрәнү аркылы алып барыла. Кеше һөнәрне үзенең кызыксынуларына, мәдәни һәм рухи ихтыяҗларына туры китереп сайлый.

***Һөнәри этика*** – ул һөнәри төркемнәрнең җәмгыятьтәге әхлакый дәрәҗәсен билгеләүче аерым бер бурычлар һәм нормалар. Һөнәри этика

кешенең аерым бер һөнәр кысаларындагы сыйфат-үзенчәлекләрен билгеләүче әхлакый нормалар һәм бәяләрне ачыкларга тиеш һәм аерым бер эшчәнлек төре өчен норма, стандарт, таләпләрне барлыкка китерә.

Һөнәри этика әхлакның нәрсә икәнлеген аңлата һәм әхлаклы булырга өйрәтә, хезмәткәрләрдә әхлак принципларын, бурыч, намус турындагы күзаллауларны формалаштыра, тәрбияли. Этика кешене башка шундый ук кешеләр белән аралашырга, коллективта яшәргә өйрәтә; әхлаклылык эталонына туры килергә чакыра.

Һөнәри этика җитештерү процессы барышында арада килеп туарга мөмкин булган катлаулы мөнәсәбәтләрне чишәргә ярдәм итәргә дә тиеш. Һәр һөнәрнең үз кыйммәтләре, традицияләре бар. Һөнәри этика кешене шуларны хөрмәт итәргә күндерә.

***Һөнәри этиканың барлыкка килүе.*** Беренче һөнәри әхлак кодексларының барлыкка килү вакыты дип урта гасырларда күзәтелгән хезмәт бүленеше чорлары – XI-XII гасырлар санала. Нәкъ менә шул вакытларда цехларда һөнәргә, башкарылган хезмәтнең үзенчәлекләренә, хезмәткәрләргә карата әхлакый таләпләр булдырыла башлаган. Дөрес, җәмгыятьтә яшәүчеләрнең барысы өчен дә аеруча әһәмияткә ия булган кайбер һөнәрләр бик борынгыда ук барлыкка килгән, димәк, «Гиппократ анты», суд функцияләрен башкаручы руханыйларның әхлакый нормалары кебек кодекслар аннан алдарак та булган инде.

Һөнәри этика барлыкка килү белән фәнни тикшеренүләр башланган, аның теориясе барлыкка килгән. Көндәлек тәҗрибә, теге яки бу һөнәр ияләре арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә салуның котылгысызлыгы аерым таләпләрнең кануннар булып формалашуына китергән. Ул процесс ничек барган соң? Аерым хезмәткәрләрнең тәртибендә күзәтелгән иң әхлаклы дип табылган адымнары норма итеп алынган, шул нормалар нигезендә стандартлар барлыкка килгән. Әлеге стандартлар ант, кодекс, устав кебек махсус документларның нигезенә салынган.

Һөнәри этика көндәлек әхлакый аңның бер формасы буларак, аерым бер эшчәнлек кысаларында барлыкка килеп, соңрак һәр һөнәри төркем әгъзаларының гамәлләрендә үсеш алган. Әлбәттә, әхлак таләпләренә җәмгыять фикере зур тәэсир ясый.

***Һөнәри әхлакның төп принциплары.*** Принциплар – гомумиләштерелгән күзаллаулар, алар ярдәмендә кеше үзенең эшчәнлеген оештыра, тәртибен формалаштыра. Принциплар һәр хезмәткәргә теләсә кайсы оешмада үзенең

этик платформасын булдырырга ярдәм итә. Барлык һөнәрләр өчен дә уртак булган шул принципларны карап китик.

- Хезмәттәшләрең, җитәкчең яки кул астыңдагылар белән мөнәсәбәтләрдә шуны истә тот: үзең белән ничек аралашуларын теләсәң, син дә алар белән шулай аралаш.

- Кул астыңдагылар арасында хезмәт ресурсларын (чимал, акча һ.б.) бүлгәндә, барысын да тигез күрергә тырыш.

- Әхлакый хата киткән икән, ул төзәтелергә тиеш!

- Кеше үзе беркетелгән оешманың үсеше өчен тырышканда гына, аның эшчәнлеге әхлаклы дип табыла.

- Башка оешмалар, төбәкләр, илләр өчен хас булган әхлак нормалары, гореф-гадәтләренә түземле булырга кирәк.

- Үз фикереңне булдыр, әмма ул мин-минлеккә, башка фикерләргә бөтенләй дә колак салмаслык дәрәҗәгә китермәсен.

- Кул астындагыларыңа карата артык таләпчәнлек, усаллык үзен акламый.

- Этик стандартларның оешма тормышына өстән кушу белән генә кереп китә алмаячагын аңлау, бары тик үзара хезмәттәшлек нигезендә генә нормаларның оешма эчендә таләп формасында беркетелүенә ирешү.

- Теләсә кайсы эшчәнлек алып барылганда, аңа капмы-каршы тора торганы да барлыкка килә, бу – җәмгыять законы. Ягъни әгәр коллективта этик нормалар артык мәҗбүриләп кертелә икән, хезмәткәрләр ул нормаларның әһәмиятен таныган сурәттә дә аларны үтәмәү чараларын эзли башлаячак.

- Хезмәттәшләреңә, кул астындагыларга ышана белергә кирәк.

- Конфликтларны булдырмый калдыру мөһим.

- Ирекле бул! Әмма синең ирек башкаларның ирекен кысрыкларлык булмасын.

- Хезмәткәр үзе генә әхлаклы булып калмый, башкаларны да этик нормаларны сакларга өндәргә тиеш.

- Көндәшеңне тәнкыйтьләү – үз коллективыңдагы көндәшме ул, әллә башка оешмаданмы, ничек кенә булмасын, ул әхлаклылыкны боза.

Әлеге принциплар һәр хезмәткәр тарафыннан үз шәхсән этик системасын булдыру өчен нигез булып торырга тиеш. Күптөрле этик кодексларның эчтәлеге дә нигезне әлеге принциплардан ала.

***Профессиональлек – шәхеснең әхлакый сыйфаты.*** Һөнәри этика – кешенең үзенең һөнәренә карата мөнәсәбәтен, һөнәри җаваплылык, намус дәрәҗәсен билгеләүче әхлакый нормалар ул. Җәмгыять бары тик матди һәм

рухи кыйммәтләр җитештерелеп торган очракта гына алга таба үсеш кичерә алачак. Менә шул җитештерү барышында аңа катнашкан кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүдә һөнәри этиканың әһәмияте зур.

Һөнәри этика хезмәт коллективындагы мөнәсәбәтләр, белгечләрнең шәхси сыйфатларын, аерым бер һөнәр өчен генә хас булган аерым нормаларны, һөнәри тәрбия бирү үзенчәлекләрен өйрәнә.

Профессиональлек һәм хезмәткә мөнәсәбәт – шәхеснең әхлакый кыяфәтен тудыручы төп факторлар. Төрле чорларда бу үзенчәлекләр төрлечә формалашкан. Мәсәлән, акыл һәм физик хезмәт капма-каршы куелган, һөнәрләр югары һәм түбән дәрәҗәлегә бүленгән. Әйтик, Борынгы Грециядә физик хезмәт иң түбән баскычта торган. Феодаль җәмгыятьтә христиан дине хезмәтне Адәм белә Хава гөнаһлары өчен җәза рәвешендә кабул иткән.

Хезмәт бурычларын тормышка ашыру вакытында кешеләр үзара әхлакый мөнәсәбәтләргә керә. Бу мөнәсәбәтләр арасында барлык һөнәрләр өчен дә уртаклары да бар.

Мәсәлән, иҗтимагый хезмәткә, хезмәт процессында катнашучыларга мөнәсәбәт. Яки төрле һөнәри төркемнәр үзара яки җәмгыять белән аралашканда барлыкка килгән мөнәсәбәт.

Һөнәрләрнең бер төркеме икенчеләреннән өстен тора алмый, анысы дөрес, әмма җәмгыять кайбер һөнәр ияләренә карата аеруча кискен таләпләр билгели – әхлакый сыйфатларының югары дәрәҗәдә булуын таләп итә. Бу кеше тормышы белән бәйле һөнәрләргә карый. Әйтик, сәламәтлек саклау, белем бирү, транспорт, хокук саклау, идарә итү өлкәләрендә эшләүчеләрдән без вазыйфаларын намус белән үтәүләрен өмет итәбез.

Хезмәткәрнең әхлакый сыйфатлары – җәмгыять өчен аның һөнәри яраклылыгының бер элементы. Аның эшенә җавапсыз каравы әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра, җәмгыятькә зыян сала, ахыр чиктә, шәхеснең үзенең юкка чыгуына, деградациягә китерә.

***Әхлакый сыйфатлар һәм базар мөнәсәбәтләре.*** XX гасыр башларында немец социологлары базар мөнәсәбәтләре шартларында барлыкка килгән яңа әхлак таләпләрен тикшергән.

М.Вебер үзенең «Протестант этикасы һәм капитализм рухы» дигән хезмәтендә капитализм рухы - ул байлык туплауны, икътисадый тормышта көндәшлек һәм яраклаша белүне хуплаучы яңа әхлакый-психологик күренеш дип атаган.

В.Зомбарт фикеренчә, базар мөнәсәбәтләре шәхеснең психологиясен һәм

әхлакый ышануларын үзгәртергә сәләтле.

Э.Фромм «базар характеры» дигән төшенчә кертә, ягъни кеше үзен товар кебек итеп хис итә башлый. Кешеләр «шәхес базары»нда товарга әйләнә, аларның да үз бәясе барлыкка килә.

Базар – ул кешеләр арасындагы товарлар һәм хезмәтләр алмашуга нигезләнгән мөнәсәбәтләр системасы. Аның төп элементлары – товар, акча, көндәшлек. Ул икътисадый ирек һәм ирекле эшмәкәрлек шартларында гына эшли.

Әгәр аерым алган дәүләттә икътисадый ирек күзәтелә икән, ул дәүләттә базар цивилизацияле, ул хаостан ерак тора. Чөнки андагы эчке мөнәсәбәтләр закон кысаларында формалаша һәм эшли. Әмма ул законнар белән генә барлык мөнәсәбәтләрне көйгә салып бетерү мөмкин түгел. Җитештерүчеләр, сатучылар һәм сатып алучылар базар икътисады кысаларында эшләгәндә, үзләре урнаштырган аерым «уен кагыйдәләрен» дә үтәргә тиешләр. Менә шул кагыйдәләр эшмәкәрләр арасындагы һәм аларның җәмгыятькә, табигатькә карата мөнәсәбәтләрен тәртипкә салучы этик нормаларны тәшкил итә дә инде.

Цивилизацияле базар мөнәсәбәтләре бер үк товарны җитештерүченең берничә булуын күздә тота, алар арасында сату базары, сатып алучылар өчен көрәш, ягъни көндәшлек яши. Бу көндәшлек намуслы булырга тиеш. Димәк, бизнеста уңышка ирешү, күбрәк җитештерү һәм сата алу товарның сыйфатын үстерү, әмма җитештерү һәм сату бәясен төшерү, көйләнгән маркетинг һәм реклама эшчәнлеген булдыру, товарны сатып алучыга мөмкин кадәр тиз илтеп җиткерүгә ирешү, гомумән, аларның барлык ихтыяҗларын канәгатьләндерү аркылы алып барылырга тиеш. Җитештерүче кеременең намуслы юл белән килүенә сөенерлек, рухи канәгатьлек алырлык булсын.

Кызганыч, Россиядә бизнес өлкәсендәге әхлакый мөнәсәбәтләр әлегә җитди килешүләр, кодекслар белән ныгытылмаган, булганнары да тиешле дәрәҗәдә эшләми. Әле тагын дәүләт тарафыннан контрольдә тотылмый торган яшерен «идән асты» предпритиеләре дә бар. Эшмәкәрләр арасында табигатькә карата салкын караучылар, экологияне саклау мәсьәләләренә игътибар итмәүчеләр, табигатьтән аның байлыкларын каерып алырга гына омтылучылар да җитәрлек.

Бәхәссез, товар һәм хезмәт базарында этик норма һәм кагыйдәләрне үтәү уңышка ирешүнең нигезендә ятарга тиеш. Чит илләрдә бу инде күптәннән шулай.

***Һөнәри этика төрләре.*** Кеше башкара торган һәр эшчәнлек төре өчен

аерым әхлакый нормалар хас.

Табиплар өчен таләпләр, мәсәлән, «Россия табибының этик кодексы»нда урын алган. Әлеге документ Россия табиплары ассоциациясе тарафыннан 1994 нчы елда кабул ителгән. Аннан да алдарак, төгәлрәк булсак, әле 1971 нче елда ук Советлар Союзы табибы анты язылган була. Гомумән, әлеге һөнәр ияләренең әхлакый йөзе һәм үрнәк булырлык этикасы борын-борыннан Гиппократ исеме белән бәйле. Бу кагыйдәләр табип белән авыру арасындагы аралашу һәм конкрет кешегә зыян салмау таләбенә нигезләнгән.

Фән һәм медицина өлкәсендә әле биоэтика дигәне дә бар. Ул табип тарафыннан башкарыла торган, кешенең тормышы һәм сәламәтлегенә бәйле эш-хәрәкәтләрнең чиктән ашып китүен кисәтә. Биоэтика – кеше тормышын биологик яктан яклау формасы. Үз-үзенә кул салулар, эвтаназия, үлем фактын билгеләү, органнарны күчереп утырту, кеше һәм хайваннар өстендә экспериментлар үткәрү, психик яткан авыруларга карата мөнәсәбәт, хоспислар оештыру, ясалма юл белән балага узу, суррогат аналар һ.б. нәкъ әнә шул өлкәгә карый. Биоэтиканың максаты – заманча биомедицина эшчәнлеген аерым кысаларда тотарлык таләпләр барлыкка китерү.

Ә менә журналистикада һөнәри әхлак әлеге һөнәр барлыкка килгәндә үк күренә башлаган. Әмма аның формалашуы гасырларга сузылган һәм бары тик журналист һөнәре киң таралыш алган чорларда гына алга киткән. Ниһаять, XIX-XX гасырлар чигендә, беренче кодекслар язылган вакытларда гына бу процесс төгәлләнгән. Журналист, белгеч буларак үсә барган саен, һөнәри әхлак ягыннан да камилләшә бара. Аның мәгълүмат чыганаклары, язма геройлары, аудитория, хакимият һәм хезмәттәшләре белән булган мөнәсәбәтләре һәртөрле җәмгыять органнары, үзе эшләгән оешма тарафыннан дөрес яки дөрес түгел дип табылырга, шуның нәтиҗәсендә аны гаепләргә һәм әхлакый җәзага тартырга мөмкиннәр. Әмма болар барысы да закон кысаларындагы административ җаваплылыкка тарту түгел, ә бәлки журналист алга таба уйлансын, күзе ачылсын, башкаларга карата әхлаксызлыкка бармасын дигән максаттан язылмаган кануннар ярдәмендә башкарыла.

Икътисадый этика исә шулай ук бик борынгы фән. Аның башлангычы Аристотель тарафыннан ук салынган. Ул үзенең әсәрләрендә улына бары тик файдалы әйберләр җитештерергә генә киңәш бирә.

АКШта автомобиль җитештерүне башлап җибәрүчеләрнең берсе Генри Форд та бәхет һәм байлык бары тик намуслы хезмәт белән генә ирешелергә тиеш, дип санаган. Бу таләп бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган.

Икътисадый этика эшмәкәрнең эш стиле, бизнеста катнашучылар белән аралашу характеры, аның социаль йөзенә булган таләпләрне берләштерә. Аның нигезендә түбәндәгеләр ята: эшмәкәр хезмәтенең үзе өчен генә түгел, башкаларга да кирәклегенә ышана; тирә-юнендәгеләрнең эшләргә теләге бар һәм алар эшли белә дип кабул итә; бизнеска ышана, аны үзенә тартып торучы иҗатка тиңли; көндәшлек кирәклеген аңласа да, хезмәттәшлекне дә кабул итә; теләсә кайсы милекне, профессиональлекне, законнарны хөрмәт итә; белем, фән һәм техниканың кирәклеген аңлый.

Россия өчен икътисадый этика аеруча әһәмияткә ия.

Хокук саклау өлкәсендә эшләүчеләрнең дә үз этикасы бар, аның нигезендә законлылык белән хакыйкилек принциплары ята. Законга тугъры юрист башкалардан ирекле. Судьялар, прокуратура органнары, закон кысаларында эшләгәндә, дәүләт хакимияте, иҗтимагый һәм сәяси оешмалардан бәйсез булалар. Юрист беркем белән дә, хәтта үз намусы белән дә килешүләргә барып, ялган нәтиҗәләр чыгарырга тиеш түгел, аның һөнәри этикасы шуны таләп итә.

Юристның эше турыдан-туры кеше намусын, дәрәҗәсен саклауга юнәлдерелгән. Шуңа күрә дә кеше шәхесен аерым кыйммәт буларак хөрмәт итүгә бәйле әхлакый нормалар юрист этикасының нигезендә ята. Аны үтәү белгечнең югары шәхси сыйфатларга ия булуын таләп итә.

Әмма бу өлкәдә каршылыклар да булырга мөмкин. Әйтик, оператив тикшерү эшендәге белгеч җинаятьчеләрне эзәрлекләү барышында яшерен күзәтү алып барырга, аларны алдарга да мөмкин. Яки адвокат үзе яклый торган кешенең чынлап та җинаятьче икәнен белгән очракта да, һөнәренә тугъры калыр өчен, ул аны судта әйтеп бирә алмый.

Хокук саклау органнарында эшләүчеләрнең әхлак бозулары турындагы хәбәрләр халыкта бик зур резонанс тудыра, бу аңлашыла да, чөнки аларга карата җәмгыять югары әхлак таләпләре куя, аларга гомерен, иминлеген ышанып тапшыра. Башкаларның язмышын хәл итүче, алардан законны үтәүләрен таләп итүчеләр, ягъни хокук саклау органнары хезмәткәрләре үзләре дә намуслы кешеләр булырга тиеш, бәхәссез.

## Журналист һөнәре этикасы

***Кодекс – журналист җәмгыятьләрендә үзлектән көйләнү механизмы.*** Этика кодекслары – дәүләт идарәсе системасында барлыкка килгән төрле эшчәнлек өчен аерым барлыкка китерелә торган һөнәри стандартларның бер өлеше. Алар хезмәт вазыйфаларын үтәүгә һәм үзара аралашуга бәйле кагыйдәләрне үз эченә ала.

Кодекслар җәмгыять өчен сыйфат гарантиясе булып тора һәм шул һөнәр вәкилләрендә булырга тиешле стандартлар турындагы мәгълүматны җиткерә. Кодексларны белеп тору әхлаксыз адымнарга барудан саклый.

Көнбатыш Европа илләрендәге журналист кодексларында түбәндәге моментларны очратырга мөмкин: намус, вөҗдан; тәнкыйть материалы язганда, объектның фикерен белү һәм аңа җавап бирү мөмкинлеген тудыру таләбе; мәгълүмат табуның яшерен юлларын куллануның тыюлуы һ.б.

«Журналистлар алдарга ярата», «журналистлар сатылып беткән, кем акча түләсә, шуның җырын җырларга әзер торалар» кебек фикерләрне еш ишетергә туры килә. Кайвакытта журналист алдында ачык ишекләр ябыла, телекамералардан качалар, ә бит болар барысы да яшерер әйбер булган өчен генә түгел. Күп вакытта журналистка ышанмыйлар, шуңа күрә аны үз араларына кертмиләр. Менә шундый хәлләр булмасын өчен журналистлар этика таләпләрен хезмәт барышында даими үтәргә тиеш.

***Журналистикадагы беренче махсус кодекслар***. Алар XIX-XX гасыр чикләрендә барлыкка килгән. Ә ни өчен нәкъ шул чорда соң? Эш шунда ки, бу вакытларда Европа һәм Америкада зур һәм куәтле газета монополияләре барлыкка килә һәм алар матбугатны халык аңы белән уйнау һәм үз ихтыяҗлары өчен файдалану чарасына әверелдерә башлый.

1908 нче елда Швейцариядәге бер газета бу турыда болай язган: «Мистер Пирсон һәм аны көндәше, «Дейли мейл» хуҗасы лорд Нордклиф Англиядә журнализмның яңа алымын кертеп җибәрделәр. Ул алым укучыны акылга ия зат итеп күрмәүдән, аңына, әхлакый сыйфатларына игътибар итми генә, һәр иртә саен аны башисемнәреннән башка, эчендә бернәрсәсе дә булмаган сенсацияле яңалыклар боткасы белән тәэмин итеп торудан гыйбарәт. Бу бик тиз сатыла. Һәрвакыт ашыгырга мәҗбүр булган кешенең барлык таләпләренә дә туры килә, чөнки ул дөньяда барган хәлләр турында тиз арада һәм гомуми характерда гына белергә тели. Акрынлап фикерләү сәләтен югалтып, ул һәр иртә саен автомат кебек шул тупас азыкны кабул итүгә күнегә». Шул рәвешчә,

укучыда аның әйләнә-тирәсендә барган хәлләр турында тулы хәбәрдарлык сурәте тудырып, матбугат кешенең акыл активлыгын чикли, аңа гадәти күзаллау кысаларыннан читкә чыгарга бирми.

Манипуляторларның үзләренә генә файдалы булган идея һәм фикерләрне укучыга шулай мәҗбүриләп тагуы демократик җәмгыятьтә, әлбәттә инде, ризасызлык китереп чыгарган. Беренче чираттта, журналистлар, болай дәвам итсә, үзләренең дә газета механизмының бер шөребенә генә әверелүләреннән куркып калган. Шуңа каршы көрәш омтылышлары беренче һөнәри кодекслар килеп чыгуга сәбәп булган да.

Беренче язма кодекс дип Франциядә 1918 нче елда кабул ителгән «Үз-үзеңне тоту хартиясе»н атыйлар. Ул Журналистларның милли синдикаты тарафыннан кабул ителгән. Дөрес, фин галиме Л.Бруун андый кодекс әле 1900 нче елда ук Швециядә дә төзелгән дип саный.

Шул ук чорларда төрле нәшриятлар һәм һөнәри җәмгыятьләр журналистлар өчен махсус очрашулар оештыра башлаган. 1921 нче елда узган шундый бер җыелышта Д.Броун халыкара кагыйдәләр кабул итәргә тәкъдим ясаган. Дөрес, очрашуда катнашучылар ул язып алып килгән вариантны кире каккан, әмма шуннан соң аның идеяләре нәтиҗәсендә Швеция, Бразилия, Финляндия һәм башка илләрдә этик кодекслары барлыкка килә башлаган. 1923 нче елда «Журнализм кануннары» исеме астында АКШта да беренче кодекс газета редакторлары җәмгыяте тарафыннан кабул ителгән.

Бу кодексларның эчтәлеген күз алдына китерик. Беренчедән, аларда матбугат җәмгыять институты дип игълан ителә, аның төп максаты итеп укучыга мәгълүмат җиткерү, аның күңелен ачу һәм дәүләт хакимиятен контрольдә тотарга ярдәм итү дип билгеләнә. Матбугатны аны чыгарырлык акчасы булган теләсә кем чыгара ала. Газетада гайбәт тарату һәм оятсызлык тыелган. Матбугат җәмгыять алдында җаваплы дип игълан ителгән.

***Журналист этикасының халыкара принциплары.*** 1954 нче елда Журналистларның халыкара федерациясе тарафыннан кабул ителгән «Журналистларның үз-үзләрен тоту принципларының халыкара декларациясе» (1986 нчы елда үзгәрешләр кертелә), шулай ук 1978 нче елда ЮНЕСКО тарафыннан кабул ителгән Декларация бүгенге көндәге күптөрле кодекслар өчен нигез булып торган.

Журналистларның 1983 нче елгы Прагадагы халыкара IV консультатив очрашуында, аннан соң Париждагы утырышта халыкара принциплар кабул ителгән. Алар барысы ун:

- гражданнарның дөрес мәгълүматка хокукы бар;

- вакыйгаларны объектив яктырту – журналистның бурычы;

- журналист социаль җаваплылыкка ия;

- журналист намуслы булырга тиеш;

- журналист аерым кешеләрнең мәгълүматка булган һәм ММЧларның эшчәнлегенә катнашу хокукын хөрмәт итә;

- башкаларның шәхси тормышын хөрмәт итә;

- җәмгыять ихтыяҗларын хөрмәт итә;

- гомумкешелек кыйммәтләрен һәм барлык мәдәниятларны да хөрмәт итә;

- сугыш һәм кешелеккә янаучы башка авырлыкларга каршы көрәшә;

- журналист яңа дөньяви мәгълүмати һәм аралашу тәртипләре яклы.

Иллеләп илдә гамәлдә йөргән этика кодексларын тикшереп, галим Т.Кунер журналистлар арасында әхлакый проблемалар китереп чыгара торган өч өлкәне аерып чыгарган. Болар – дөреслек эзләү, җаваплылык һәм сүз иреге. Дөреслек эзләү төгәл, объектив һәм дөреслеккә туры килгән мәгълүматны гына тарату дигәнне аңлата. Җаваплылык массакүләм мәгълүмат чарасы реклама бастыручылар яки хакимияткә түгел, ә бары тик үз аудиториясенә генә хезмәт итәргә тиешлекне белдерә. Ә сүз иреге хакыйкатькә тугърылыкны аңлата.

Әлбәттә, Россиядә бу таләпләр әлегә тулысынча үтәлә алмый, чөнки безнең мәгълүмат чараларыбыз җитәрлек дәрәҗәдә бай, ягъни бәйсез түгел. Шуңа күрә дә алар еш кына «акча капчыклары»на барып егылырга, иганәчеләр белән эшләргә, газета мәйданын реклама белән тутырырга мәҗбүр. Ә бит реклама белән шөгыльләнү үзе юк журналистика белән туры килми, каршылыкка керә, дигән фикер бар. Кызганыч, ул фикергә җитәрлек дәрәҗәдә колак салучы гына юк.

***Россиядә журналистлар өчен этика кодекслары.*** Россия журналистлары электән килгән тарихи документ – М.В.Ломоносовның «Журналистларның бурычлары турындагы уйланулар...» дигән трактатын яхшы белә. Әмма XX гасырның 80-90 нчы елларына кадәр ул Россиядә бердәнбер шундый документ булып калган да.

Россиядә 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң барлык буржуаз газеталар ябылып, алар урынына яңа совет матбугаты барлыкка килгәч, журналистика тулаем алганда партия һәм хөкүмәт органнары кушканны гына сөйләүчегә әверелде. Ә бу шартларда һөнәри этика партия максатларына яраклы әхлакка хезмәт итү дигәнне аңлатты. Әхлак кодекслары ролен партия юллаган документлар үтәп килде. Һөнәри этиканы боларга гына кайтарып

калдыру да дөреслеккә туры килмәс, чөнки журналистлар арасында коллегаларына карата ихтирамлылык, көн кадагына суккан мәсьәләләрне күтәргәндә кыюлык, дөреслеккә омтылыш кебек сыйфатлар да булмады түгел. Әмма алар еш кына матур сүзләр артына яшереп калдырылды, алгы планга ялагайлык, хакимият вәкилләренә ярарга тырышу чыкты.

Бары тик 1988 нче елда гына беренче тапкыр СССР Журналистлар берлегендә Һөнәри этика һәм хокук буенча совет оештырыла. 1989 нчы елның декабрендә әлеге Советның хуплавы белән Журналистлар берлеге съездында этик таләпләрнең беренче тупланмасы – Совет журналистының һөнәри этика кодексы кабул ителә. Шул заманга хас булганча, бу документта «фикерләр плюрализмы», «халык ихтыяҗлары», «хәбәрдарлык», «яңа мәгълүмати тәртип» дигән ялтыравык төшенчәләр бар, әмма шул ук вакытта Кодекс социаль җаваплылык, дөреслек, объективлык, вөҗдан, шәхес намусын яклау, гомумкешелек кыйммәтләрен хөрмәт итү, һөнәри хезмәттәшлекне дә таный.

Кодексны кабул иткәндә, андагы таләпләрне бозу очраклары булса, беренчел журналистлык оешмалары ул эшләрне тикшерер, гаепләләргә кисәтү кебек чаралар кулланыр, хәтта журналистлар берлегеннән чыгара алыр дип фаразланган. Тик озак та үтми, бу Кодекс онытыла.

Ниһаять, XX гасырның соңгы 10-15 елында алып барылган үзгәртеп кору җилләре массакүләм мәгълүмат чараларына да килеп кагылды. Кагылып кына калмады, давыл булып аны җиргә екты. Партия цензурасының юкка чыгуы, чагыштырмача ирек, базар мөнәсәбәтләре, шулар нәтиҗәсендә тиражлар кимү, кәгазьгә, типография чыгымнарына бәя арту, яңа төр басмалар барлыкка килү, тормышның артык кыйммәтләнүе, аннан да бигрәк, әхлакый кыйммәтләрнең җимерелүе, югала баруы журналистларны да үзгәртми калмады. Журналистика инде хакимиятнең түгел, аерым бер коммерция оешмаларының, җинаятьчел төркемнәрнең коралына әверелмәсен өчен, ниндидер адымнар ясалырга тиеш иде.

Шуңа да һөнәри этика мәсьәләсе берничә елдан тагын калкып чыга. Чөнки аның кирәклеген, котылгысызлыгын аңлаучылар шактый була. 1994 нче елның 4 февралендә Мәскәү басмаларында эшләүче атаклы журналистлар бергәләшеп Журналистларның Мәскәү хартиясен булдыра һәм аңа кул куя. Хартия, дөньядагагы башка шуның кебек һөнәри этика кодексларындагыча, берничә таләпне кискен куя: мәсәлән, журналист үз һөнәрен дәүләт органнарында яки сәяси партияләрдә аерым вазыйфа башкару белән беррәттән алып бара алмый; кулына корал алу белән журналист булудан туктый.

Әлеге Хартия ул вакытта инде Россия журналистлар берлеге җитәкчелеген Һөнәри этика кодексын булдыруга этәрә. Ул Кодекс 1994 нче елның 23 нче июнендә Россия журналистлары конгрессында кабул ителә.

Әлеге кодексны, демократия чәчәк аткан чит ил кодексларыннан күчереп ясалганга күрә, безнең җирлек, безнең шартлар өчен бик үк туры килеп бетмәгән кагыйдәләр тупланмасы гына дип атаучылар да табылды. Әмма ничек кенә булмасын, бүгенге көндә әлеге Кодекс Россия журналистлары, шул исәптән, татар журналистлары да үзара мөнәсәбәтләрне шуның ярдәмендә тәртипкә салырга тиешле документ булып тора.

Ул Кодекста 10 маддә бар. Беренчедән, журналист бары тик дөреслегенә үзе ышанган мәгълүматны гына тарата ала, фактлар һәм башкаларның яки үз фикерләрен аерып күрсәтә. Икенчедән, һөнәри вазыйфаларын үтәү барышында табылган конфиденциаль мәгълүматны үз ихтыяҗларында файдалана алмый. Журналистлык һәм реклама өлкәсендәге эшчәнлек бер-берсе белән һичничек тә яраша алмый. Ачык көндәшлек законнарын саклаган хәлдә, журналист коллегаларына зыян салырлык адымнардан сакланырга тиеш. Өченчедән, журналист бары үз коллегаларының сүзләренә генә колак сала, хакимият яки башка кешеләр тарафыннан алып барылган басымга игътибар итми. Дүртенчедән, журналистның һөнәри статусы аңа дәүләт идарәсе, закон чыгару һәм суд органнарында эшләргә мөмкинлек бирми.

Этик кодексларның барлыкка килү сәбәпләренең берсе – ул, бер яктан, гамәлдәге законнар колачлап бетермәгән «ак тап»ларны юкка чыгару, икенчедән – хокук бозу дип атап булмый торган әхлаксызлыкны кисәтергә омтылу. Шуны да әйтү кирәк, гамәлдәге Кодекс «Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы» Закон, Россия Конституциясе, Гражданлык һәм Җинаять кодекслары белән кайбер урыннарында аваздаш та. Ә бит этик нормалар административ көчкә ия булырга тиеш түгел, алар хезмәт килешүләрендә чагылыш тапмый. Димәк, этика кодексының да төгәлләп бетерәсе урыннары шактый.

***Мәгълүмат чыганагы һәм журналист арасындагы мөнәсәбәтләр.*** Кеше, мәгълүмат чыганагы буларак, журналист сораган һәр сорауга да җавап бирмәскә мөмкин. Бу – аның хокукы. «Сөйләштерү» өчен журналистка аерым осталык кирәк, чөнки әңгәмәдәшне куркыту да, юри кыздыру да, матбугат ярдәмендә шәхси үч алырга чакыру да тыелган. Әгәр кеше уңай материал өчен дә мәгълүмат бирүдән баш тарта икән, моңа колак салырга кирәк. Сәбәбе төрлечә булырга мөмкин, бәлкем ул кешегә әйләнә-тирәдәгеләре начар

мөнәсәбәттәдер, көнләшүчеләре дә бардыр, аны хөрмәт итмиләр, эшен яхшы башкара дип санамыйлардыр. Ә сез аның турында мактап язарга уйлыйсыз. Әлбәттә, ул кеше мәгълүмат бирүдән баш тартачак. Шулай ук халыкка чыгарырга ярамаган серләрне сакларга омтылу яки геройның артык тыйнаклыгы да каршы килүгә сәбәп булыр торырга мөмкин. Башка журналистларның бу кешегә карата моңа кадәр булган начар мөнәсәбәте, әхлаксызлыгы да аның журналист белән сөйләшергә теләмәвен аклый ала. Боларның барысын да ышаныч яулап, эчкерсез сөйләшү аркылы гына җиңеп чыгарга мөмкин.

Мисал өчен, кеше үзе турында сөйләргә теләми икән, сүзне ул эшләгән оешмадан, хезмәттәшләреннән башларга ярый. Болай эшләү киеренкелекне киметергә ярдәм итәр. Шуннан соң алга таба сөйләшү барышында әңгәмәдәш үзе турында сөйләргә риза булырга да мөмкин.

Әңгәмә барышында журналистның активлыгы һәм әхлаклылыгы ул биргән сорауларда, әңгәмәдәш җавапларына реакциясендә, мимика, гәүдә торышы һәм хәрәкәтләрендә чагылачак. Сорауларның урынлы булуы һәм әхлакны бозмавы – журналистны профессионал итеп күрсәтүче сыйфатларның берсе.

Әңгәмәдәш җавап бирә алмаслык сораулардан качарга кирәк. Шулай ук артык тапталган, кызыксыз формада җавап бирерлек сораулар да әңгәмәдәшне кимсетә, ә газетада басылып чыккан җавап аның образын боза гына. Журналистның сөйләшү тоны да ялагайлануын да, киресенчә, үзен югары куюын да күрсәтмәскә тиеш.

Әңгәмәдәшнең ышанычын яулап алганнан соң, аны явыз максатта куллану, кешенең хисси халәтеннән файдаланып, кирәгеннән артыгын сөйләтеп калырга тырышу – болар барысы да этика нормаларын бозу.

Бик күп вакытларда әңгәмәдәшләр «монысын газетада бастырмассыз (радио- яки телетапшыруны монтажлаганда төшереп калдырырсыз)» дип, кайбер мәгълүматларны журналистка сер итеп кенә сөйли. Журналист бу үтенечкә колак салырга тиеш, әлбәттә. Әмма бу мәгълүмат аңа бик кызык һәм кирәкле тоелса, ул аны башка чыганаклардан эзләп таба ала. Ул вакытта әхлак та бозылмый, кызыклы мәгълүмат та югалып калмый. Әмма бу мәгълүмат әңгәмәдәшнең шәхси, эчке серләре булмаска тиеш, алары бары тик аның рөхсәте белән генә басыла ала.

Журналист өчен мәгълүмат чыганакларының коллектив формасы да кулланыла. Җыелыш, утырыш, конференцияләр вакытында мәгълүмат

туплаганда, ул шуны истә тотарга тиеш: анда ишеткәннәр дөреслеккә туры килмәскә дә мөмкин. Әйтик, бер кеше тарафыннан әйтелгән фикер бөтен коллектив фикере булып яңгырау куркынычы бар, ди. Димәк, аларны башка чыганаклардан да эзләп, дөреслеген расларга яки кире кагарга кирәк. Шуннан соң гына ММЧ аркылы таратырга була.

Документлардан мәгълүмат туплауның да үз таләпләре бар. Иң элек моңа хуҗасының рөхсәте булырга тиеш. Рөхсәте булуны язмада да аерым билгеләп китәргә мөмкин, болай эшләү журналистка карата хөрмәтне арттыра, хезмәттәшләре өчен үрнәк булып тора. Материалда документтан өзекләр, аңа карата бәя, журналист фикере – һәрберсе аерылып ятарга тиеш.

Тәнкыйть язмасы өчен мәгълүмат туплаганда, журналистлар еш кына әңгәмәдәш сөйләгәннәрне аннан рөхсәт сорамыйча гына диктофонга яки камерага яздыра. Болай эшләү әхлаклы адыммы, әллә юкмы? Журналистлар бу сорауга төрлесе төрлечә җавап бирәчәк, әлбәттә.

Ничек кенә булмасын, журналист төрле этика кодексларында куелган таләпләрне үтәргә тиеш. Ягъни башкаларның намусын һәм дәрәҗәсен хөрмәт итә, алар белән аралашканда әдәпле сөйләшә, эчке тормыш серләренә үтеп керергә омтылмый, инде андый мәгълүматка ирешә калса да, бары тик иҗтимагый һәм аерым кешеләрнең хокуклары һәм законлы ихтыяҗларын яклау максатында гына аларны халыкка тарата ала, диелгән кодексларда.

Фактларның дөреслеген тикшерү, документлар яки башка чыганаклардан алынган мәгълүматларны үзгәртмичә, эчтәлегенә зыян китермичә, яңа мәгълүматларны үзе уйлап чыгармыйча халыкка тарату – аның бурычы.

***Журналист һәм аудитория арасындагы мөнәсәбәтләр.*** Журналистның иң беренче бурычы – халыкка дөрес һәм хакыйкый мәгълүмат җиткерү. Факт, комментарий, фикер, фаразлаулар барысы да аермачык булып күренеп торырга тиеш. Димәк, ул чынбарлыкны объектив рәвештә яктыртырга тиеш. Фактларның чын мәгънәсе югалмасын, яшерелмәсен, үзгәртелмәсен. Бу максатын тормышка ашыру өчен, ягъни аудитория аның материаллары аша дөнья турында мөмкин кадәр дөрес һәм төгәл күзаллау булдыра алсын өчен, журналист үзенең иҗади мөмкинлекләрен тулысынча файдалана.

Мәгълүмат – куллану предметы түгел, ул иҗтимагый байлык. Журналист үзе тараткан мәгълүмат өчен җавап тота. Бу җаваплылык массакүләм мәгълүмат чараларын контрольдә тотучы оешмалар каршында булудан бигрәк, киң җәмәгатьчелек алдында тотыла. Журналистның социаль җаваплылыгы

аннан һәр очракта да үзенең әхлакый аңы таләпләренә туры китереп эшләвен таләп итә.

Закон белән тыелмаган теләсә кайсы мәгълүмат халык милке булырга, халык үзе массакүләм чаралар эшчәнлегендә катнаша алырга тиеш. Икенчесе хаталарны төзәтү яки җавап бирү мөмкинлеге булсын өчен таләп итеп куела.

Журналист җәмгыять ихтыяҗларын, аның демократик институтларын һәм иҗтимагый әхлакны хөрмәт итәргә тиеш. Шул сәбәпле үзенең материалларында усаллык, явызлык, көч куллануны күрсәтүдән тыела. Мәсәлән, кеше яки хайваннарның үлемен, аларны физик көч кулланып мыскыл итү, газаплау очракларын, шулай ук җинаять, фаҗигадан соң калган күренешләрне, кыйнау эзләрен күрсәтергә ярамый.

Медицина өлкәсендәге ачышлар һәм уңышлар турында сөйләгәндә дә сак булу кирәк: алар аудиториядә курку яки сәламәтләнүгә карата ялган өметләр уята күрмәсен.

Журналистларның кайбер адымнары һөнәри этика тарафыннан гражданнарның мәгълүмат алуга булган хокукын бозу дип табылырга мөмкин. Әйтик, журналист алдан ук белеп ялган мәгълүмат таратса да, киресенчә, алдан белмичә, әмма аның дөреслеген тикшерергә теләмичә генә ниндидер чыганаклардан белгән мәгълүматларны аудиториягә җиткерсә дә, этиканы бозган дип саналачак. Тапкан мәгълүматны яшереп калдыру да, аның эчтәлеген бозу, чыганагын дөрес күрсәтмәү, шулай ук төрле материалларга карата алынган полемик рухтагы кайтавазларны, җавапларны бастырмыйча яшереп калдыру да журналистның һөнәри дәрәҗәсен төшерә. Хатлар белән эшләгәндә дә сак булу таләп ителә: автор ризалыгыннан башка аның язмасының төп мәгънәсен үзгәртергә ярамый. Журналистның укучылар исеменнән хатлар язарга яки үз материалын башка реаль кеше исеме астында чыгарырга да әхлакый хокукы юк.

***Журналист һәм язма геройлары арасындагы мөнәсәбәтләр.*** Еш кына материал геройлары журналистка үпкәләп кала. Бу очракта ул кешеләрне материал герое түгел, ә корбаны дип атасак дөресрәк булыр. Бу очракта исем-фамилияләрдә киткән хаталар турында түгел, ә алардан авыррак очраклар турында сүз бара. Әйтик, геройларның шәхси тормышы турындагы яшерен мәгълүматларны халыкка таратып, журналист ул кешеләрне гомергә хурлыкка калдырырга мөмкин. Шуңа да кайбер очракта геройларны уйлап табылган исемнәр артына яшерү таләп ителә. Шәхси тормыш дигәндә, журналистлар шәхси һәм гаилә серләрен, шул исәптән никах һәм интим мөнәсәбәтләрне,

сексуаль ориентация, дини карашлар, дуслык мөнәсәбәтләре, буш вакытны уздыру чаралары, хат язышу, телефоннан, интернеттан аралашуны күздә тота.

Аеруча әле суд карары чыгарылмаган очраклар турында язганда сак булу кирәк, чөнки баштарак гаепле дип күрелгән кешене суд акларга да мөмкин, әмма әгәр журналист аны баштан ук гаепле дип язса, җәмгыять инде бу кешене барыбер да җинаятьче итеп кабул итәчәк. Шул ук вакытта корбаннарның исемнәрен атаудан һәм аларны танып булырлык итеп сурәтләүдән дә тыелырга кирәк. Әгәр корбаннар балигъ булмаганнар арасыннан булса, журналист аеруча сак булырга тиеш.

***Журналист һәм коллегалары арасындагы мөнәсәбәтләр.*** Коллегалар белән аралашу таләпләрен икенче төрле итеп «корпоратив этика» дип атарга мөмкин. Дөрес, теләсә кайсы иҗади бергәлектә көндәшлек рухы хөкем сөрә. Шуңа да бердәмлек, дуслык турында сөйләү бераз ясалмалылык булып тоелырга да мөмкин. Әлбәттә теләсә кайсы журналистның үзен танытасы килә. Шуңа да ул көндәш булырлык хезмәттәшләрен алдан ук күреп ала, аларны уздырырга тырыша. Иҗади коллективны кайбер чакта кулланыла торган «елан оясы», «террариум» дигән сүзләр белән атарга ярамаса да, югары амбицияле кешеләрнең үзара каршылыкка кереп торачагы алдан ук билгеле. Менә шул каршылык бәрелешкә барып терәлмәсен өчен журналистикада корпоратив принципларны билгеләү-ачыклау ихтыяҗы килеп чыга да.

Җәмгыять алдындагы бурычларын тормышка ашыру барышында журналист аның ышануларына каршы килгән эштән баш тарта ала, аерым кешеләрнең гомумкешелек кыйммәтләренә каршы килә торган шәхси ихтыяҗларын якламый. Нәшир яки редакция җитәкчелеге кушкан эшләр дә әнә шул иҗтимагый әхлак таләпләренә каршы килсә, журналист алардан да баш тартырга тиеш.

Кызганычка каршы, боларны тормышка ашыру бүгенге чорда – массакүләм мәгълүмат чарасы товарга әйләнгән вакытта аеруча авыр. Әйтик, әгәр баш редактор фикере белән каршылыкка керсә, журналист үз материалын бастыра алмаячак. Барыбер да үз дигәнен итәргә тырышса, аны эштән китәргә мәҗбүр итәчәкләр яки штатын кыскартачаклар.

Журналист интеллектуаль милекне хөрмәт итә, димәк, плагиатка каршы тора. Плагиат ул чит автор материалларын куллану гына түгел. Әйтик, интернеттан «авторсыз» материалларны алып, аларны үз фамилияң белән яки бераз гына редакциялəп бастырып чыгару да плагиат икәнен истә тотарга кирәк.

Журналист үз һөнәренең дәрәҗәсе турында онытмаска, хезмәттәшләренә яки журналистика исеменә тап төшерә торган эшләр белән шөгыльләнмәскә тиеш. Иҗади «ярыш» вакытында да коллегаларының ышанычын саклый, аларга һөнәри бурычларын үтәүдә комачау итми, зыян салмый, киресенчә, аларның белемен, һөнәри дәрәҗәсен күтәрүдә булыша, авыр хәлдә калсалар, ярдәмгә килә икән, ул этиканы бозмый дигән сүз. Шул ук вакытта һөнәри ярдәм дөреслеккә һәм хаклыкка хезмәт итү белән капма-каршы килмәскә тиеш, ягъни хезмәттәшенә ярдәм итәм дип, журналист ялган сөйләүгә яки башка әхлаксыз адымнарга бара алмый.

Һөнәри этик нормаларын бозуның тагын берничә төрен мисалга китерик. Мәсәлән, журналист үзенә яки якыннарына кирәк булган өчен башка журналисттан мәҗбүриләп дөреслеккә туры килмәгән эчтәлектәге материалны яздырта һәм бастырта ди. Яки хезмәттәшенең материалын үзгәртеп редакцияли һәм, аны кисәтеп тә тормыйча, халыкка тарата. Шулай ук хезмәттәшләренең псевдонимнары ачу, башкаларның әсәрләрен тулаем яки өлешчә үз фамилиясе астында бастыру, бер үк материалны алдан килешмичә берничә редакциягә тапшыру да корпоратив этиканы боза.

Кайбер журналистлар бер редакциядәге коллегаларын яки башка оешмадагы журналистларны халык алдында ямьсез сыйфатта күрсәтергә ярата, ягъни, мин менә нинди оста иҗатчы, ә алар сәләтсез, булдыксыз. Иҗади һәм әхлаклы көндәшлек кысаларына сыймаган шундый адымнардан ерак торырга кирәк.

***Татар журналистикасында әхлак нормалары.*** Татар журналистларының аларга гына хас, алар өчен махсус кабул ителгән нормалары юк. Әмма җәмгыятьнең үз язылмаган кануннары була. Татар менталитеты, ышанулары, үз-үзен тоту, фикерләү рәвеше элек-электән шушы җәмгыятькә генә хас аерым нормалар тудырмый калмаган. Аларның, әлбәттә, Ислам дине белән бәйләнештә яшәвен дә истә тотарга кирәк. Мондый гомуми әхлак, аңлашыла ки, һөнәри әхлакка да йогынты ясамый калмый, чөнки һәр һөнәри әхлак гомуми әхлакның бер өлеше бит ул.

Димәк, татар җәмгыятендә урын алган менә шул гомуми әхлак нормалары татар журналистикасында да чагылыш табарга тиеш. Әмма, кызганычка каршы, татар журналистикасына хезмәт итүче профессионаллар бүгенге көндә рус һәм чит ил журналистикасына, алар кулланган алымнарга, димәк, алар табынган нормаларга күбрәк омтыла. Шуның нәтиҗәсендә татар җәмгыяте өчен генә хас булган әхлакый нормалар читтә кала, онытыла. Югыйсә, татар

тормышына хезмәт итә торган татар телле татар журналистикасының татарга хас әхлакый кагыйдәләргә тугъры калуы бүгенге көндә әһәмиятлерәк, мөһимрәк, кирәклерәк түгел микән?!

Инде шул язылмаган кануннарга якынрак килик. Иң беренче чиратта, әлбәттә, татар журналистикасына журналист белемендә «пычрак мәгълүмат» дип атала торган мәгълүматны кабул итмәве хас иде. «Мәгълүмати пычраклык»ның төрләре күп. Шулар арасыннан порнографик һәм эротик эчтәлектәге материалларны аерып алыйк. Россия журналистикасы порнографияне тыйса да, эротикага «яшел юл» ача. Шул юнәлештә чыгучы басмалар да, башка эчтәлектәгеләре белән беррәттән эротик материаллар биреп баручы газета-журналлар да бар хәзер. Татар матбугаты да бүген әлеге юнәлешкә йөз тотмакчы. Бу, беренче чиратта, секс, интим тормыш серләре турында язуда, икенчедән, артык әдәпсез кыяфәттәге фотосурәтләр бастыруда чагыла.

Беренче очракта эшчәнлек сексуаль һәм гаилә тәрбиясе бирү сылтавы белән алып барылса, чынлыкта әдәп-әхлак кагыйдәләре, шулай ук совет тормышы таләпләре белән матбугатта моңарчы тыелып килгән тема ярдәмендә укучыларны үзенә тартырга, күбрәк тираж җыярга, гади генә итеп әйткәндә, акча эшләп калырга омтылудан гыйбарәт.

Инде мисалларга тукталыйк. «Уртак түшәк», «Акчарлак» газеталары инде ничә еллар укучыларын атаклы кешеләрнең интим тормышы турындагы фактлар белән таныштырып тора. Башта «Уртак түшәк»тә чыккан, аннан әлеге газетага реклама максатыннан «Акчарлак»та да күчереп бастырылган «Әлфия Авзалова: «Үзем ямьсез булсам да, ирләрем матур иде» дигән әңгәмәдә (Акчарлак, 2004, 16 апр.) татар халкының инде легендага әверелгән җырчысының интим тормышы турында әдәпле кеше белергә дә теләмәслек нинди генә фактлар юк!

Тележурналист Илфат Фәйзразманов белән әңгәмәсен дә автор шул темадан башлап җибәргән (Акчарлак, 2004, 23 апр.). «Секс белән шөгыльләнәсезме?» – дип, үзе әйтмешли, үгезнең мөгезеннән тотып башлый ул сүзне. Әңгәмәдәшнең аптырап, каушап калуын күргәч, аклангандай: «Авырудан соң дип әйтүем...» – дип акланып куя. Мондый сораулар әдәпсез генә булып калмыйча, әңгәмәдәшнең кешелек дәрәҗәсенә тия, аның укучылар алдындагы хөрмәтле исемен пычрата түгелме соң?!

Татар журналистикасы этикасы өчен төп булган принципларның берсе - геройларның эчке тормышында казынмау. Татарда гайбәт сөйләргә ярамый,

дигән халык педагогикасы нигезләре бар. Ислам дине дә гайбәт сөйләүне тыя. Ә эчке тормышта казыну, геройларның үзләренә генә билгеле, күп очракларда беркем дә белергә тиеш булмаган серләрен бөтен халыкка тарату, матбугат битләрендә шулар турында тәмләп сөйләшү шул гайбәт сату дигән сүз инде ул. Татар журналисты моннан тыела килде. Әмма гасырлар чигендә бу язылмаган канунны да җимерүчеләр барлыкка килә бара.

Авторның артык төпченүчәнлеге, бәйләнчеклеге, әдәпсезлеге геройда гына түгел, укучыда да уңайсызлык хисе тудыра, танылган кешеләрне шулай авыр хәлдә калдырганы өчен, укучы да кызарырга мәҗбүр ителә. Җырчы Резидә Шәрәфиева белән булган әңгәмәдә (Акчарлак, 2004, 27 февр.) журналист аннан: «Ә син кияүдәме соң?», «Әле һаман кияүдә түгелмени?» дип, бәлки, кешенең бик авырткан урынына тия торгандыр!? Шул ук автор телевидение дикторы Эльза Әхмәтҗановадан «Ничек кияүгә чыктың?» дип сорый, герой җавап бирергә теләмәгәч, «Беренче мәхәббәтеңә кияүгә чыктыңмы әллә?» дип аптырата, анысына да төгәл җавап алмагач, «Беренче мәхәббәтең Апаста яшиме, исеме ничек?» дип тинтерәтергә тотына, «Ә чын мәхәббәтең кайчан булды?» дип азаплый. Эльза Әхмәтҗанова бу сорауларның берсенә дә диярлек төгәл, журналист көткән җавапларны бирми. Ә, бәлки, журналистка шул кирәктер дә: геройның аптырап калуы, сорауларны җавапсыз үткәреп җибәрүе, каушавы аңа үзенчә нәтиҗәләр ясарга ярдәм итәдер. Сүз дә юк, автор чит ил журналистлары үрнәгендә, «сары матбугат» дип исем алган таблоидлар рухында, скандал журналист репутациясен тудырып эшли. Әмма татар журналистикасы өчен бу алай ук кирәк микән? Ни өчен читләр тәҗрибәсенең инде алар үзләре дә баш тарткан, сыйфатсыз дип тапкан моментларын гына үрнәк итеп алырга омтылыш яши соң?

Татар журналистикасы өчен элек-электән сүгенү сүзләре куллану, дорфалык үз түгел. Гомумән, әдәпле кеше беркайчан да үз фикерен оятсыз сүзләр ярдәмендә белдермәячәк, дип хисапланыла. Татар журналистикасы әлегә кадәр шулай эшләп килә дә, матбугатка сүгенү сүзләре чыкмый, әллә журналистның шәхси намусы, әдәп дәрәҗәсе, әллә редакторлар катнашы белән сөзелеп калдырыла. Әмма  дорфалык очраштыргалый. Шул ук «Акчарлак»ка әйләнеп кайтыйк. «Пирамида түзде» дигән язмада (Акчарлак, 2004, 16 гыйнв.) автор болай дип яза: «Гүзәл Уразова, син инде Кристина Агилера кебек киенгәнсең икән, гәүдәң идеаль булырга тиештер. Тиккә генә мин синнән: «Корсакка узмадыңмы, сәхнәдән шулай күренә!» – дип сорамадым бит». Нәрсә бу? Җырчының буй-сыны да, нәрсә киюе дә, ахыр чиктә, балага узу-узмавы да

үз эше түгелмени? Ярар, бу фикерләрне кухняда үзара сөйләшкәндә берәрсе әйтеп тә куйсын, ди инде. Тик бу югары белемле журналист каләменнән чыгарга тиешле сүзләрме соң? Җырчы Салаваткa: «Ә бит улың Рөстәм үзеңә охшамаган?..» - дип әйтү дә (Акчарлак, 2004, 6 авг.), Айдар Галимовтан: «Син тырнаклар да үстерәсең ахры, шундый модамы әллә?» – дип сорау да (Акчарлак, 2004, 23 гыйнв.) аларның авторы - журналист турында ул татар журналистикасының этика кагыйдәләрен белеп эш итә, аларны үти дип әйтергә һич урын калдырмый.

Сорау әдәпле тонда әйтелеп тә, әңгәмәдәшне җәмгыятьтәге әхлак нормаларын бозуга чакырырга мөмкин. Мисал өчен, шул ук «Акчарлак»та басылып чыккан бер интервьюга күз салыйк. «Нурия Ирсаева: «Фидан белән минем хакта гайбәтне күп сөйләделәр» дигән язмада «Башкортстаннан Зәйнәп Солошина» дип күрсәтелгән автор актрисага сәхнәдәге партнеры турында «Фидан Гафаровның нинди тискәре сыйфатларын атый аласыз?» – дигән сорау бирә. Сөенеч, актриса провокациягә бирелми, актер турында гайбәт сөйләргә алынмый (Акчарлак сайты, 2013, 7 ноябрь // http://акчарлак-газета.рф/tt/node/415).

Гомумән, журналистлар андый сорауларны бирергә яраталар. Бәлкем, сорауга җавап булмаса яки әңгәмәдәштә авыр хисләр уянса, елап җибәрсә, интервьны кәгазь битенә төшергәндә, ул урыннарын язып тормам дип уйлыйлардыр. Әмма журналист бәхетенә дисәк тә дөрес булыр, әңгәмәдәшләр әдәпле, сабыр булып чыга, андый күңелгә ошамый торган сорауларны акрын гына узып китәргә җай табалар. Мисал өчен, «Ләбиб Лерон: «Хыянәт итмәгән ирне күргәнем юк» язмасында Назилә Хуҗинаның «Сезнең Бәхтияр исемле авыру улыгыз бар. Аның хәл-әхвәле ничек?» дигән соравын әңгәмәдәш, шаян холкына туры китереп, «Военкоматтан повестка җибәреп борчымыйлар» дигән җавап белән ябып куя (Акчарлак сайты, 2013, 18 июль // http://акчарлак-газета.рф/tt/node/318).

Яки Габдерәхимнең Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгының аппарат җитәкчесе Кадрия Идрисова белән әңгәмәсенә тукталыйк. Журналистның «Сезгә бала хәсрәте күрергә язган икән. Кызыгыз юл һәлакәтендә вафат булган дип ишеттем», - дип әйтүе дә шул хәсрәтләрне яңарту, әңгәмәдәшне эмоциональ яктан селкетеп җибәрү өчен генә кулланылмый микән? (Акчарлак сайты, 2013, 5 февр. // http://акчарлак-газета.рф/tt/node/140).

Әмма журналистларның барысы да әхлак нормаларын боза,

әңгәмәдәшләрнең шәхси тормышы турында күбрәк белергә омтыла, хәтта андый мәгълүматларны аларны провокацияләү өчен куллана дигән сүз түгел. Сәнгать кешеләре белән (күп очракта татар матбугатында әхлак бозу нәкъ әнә шул өлкәдә күзәтелә) чын профессионалларча корылган әңгәмәләр, шулар нигезендә язылган очерклар, мәкаләләр дә бар. Бу урында мисалга «Гөлнара Сабирова: «Шигырь язу – акча эшләү чыганагым түгел»« дигән материалны китерергә мөмкин (Ватаным Татарстан, 2013, 6 сент.). Авторы Алсу Хәсәнова яшерен фактлар белән дә «уйнамый», укучыга көтелмәгән гайбәт сүзләрен дә җиткерми, җырлар өчен бәхетсез мәхәббәт турында шигырьләр язучы яшь туташка аны кызартырлык, уңайсыз хәлгә куярлык сораулар да бирми. Әмма аңа карап кына язма кызыклыгын югалтмаган, тоныкланмаган, романтик, әмма җирдә ике аягы белән нык басып торучы җыр авторы турында ихлас тасвирнамә килеп чыккан.

Журналистлык вазыйфаларын үтәгәндә түгел, үзара сөйләшкәндә дә тәрбияле кеше әдәплелек сакларга тырыша. Әңгәмәдәшне, димәк, материалның героен хөрмәт итү сыйфаты шул рәвешчә журналистка да хас булырга тиеш кебек. Татар журналистикасы этикасының алтын кагыйдәләрен үтәп килүче журналистлар шулай эшли дә. Мисалга «Шәһри Казан» газетасында басылган «Яраларыгызга кагылмадыммы?» мөхбирнамәсенә (2004, 28 февр.) тукталыйк. Анда автор (Фәнсөя Сафина) балаларын әниләрсез генә үстерүче ялгызак әтиләр белән булган очрашу турында сөйли һәм шунда туган фикерләре белән уртаклаша. Материалда әлеге әтиләр белән булган сөйләшүдән өзек тә китерелә: «- Нишләп кабат өйләнмәдегез? – дим һәм элекке яраларын яңартмадыммы икән инде дип, читенсенеп аңа карыйм». Күргәнебезчә, автор артык сүз әйтеп, геройларның күңелләрен яралаудан курка. Тагын бер әңгәмәгә тукталыйк. «Язмышка үпкә» дип аталган ул сөйләшү (Акчарлак, 2004, 20 февр.), җырчы Әлфис Кыямов вафат булгач, аның хатыны белән булган әңгәмәдән гыйбарәт. Авторлар (Энҗе Басыйрова, Айгөл Габдрахманова) яңа гына искиткеч зур югалту кичергән ханым белән бик әдәпле сөйләшәләр, этика нормаларына сыешлы сораулар бирәләр.

Татар матбугатындагы этик нормалар турында сүз алып барганда, дуслык, үзара хезмәттәшлек, ярдәм итешү мөнәсәбәтләре турында әйтми калу ярамас. Бу принциплар журналистлар бергәлекләрендә электән яшәп килгәннәр. Бер карасаң, газета-журналлар көндәшлек атмосферасында яшәсә, журналистлар арасында үзара ярдәм итешү булмаска тиеш кебек. Мисал өчен, республикада үткәрелгән чарага бара алмаса, журналист башка басмалардагы коллегаларына

чылтыратып яки очрашып, шул чара турында мәгълүмат ала ала. Мондый хезмәттәшлек фотохәбәрчеләр арасында аеруча киң таралган. Әһәмиятле вакыйгага үз газетасының фотохәбәрчесеннән башка гына килгән журналист башка массакүләм мәгълүмат чарасының фотохәбәрчесенә мөрәҗәгать итеп, фотосурәт сорап алырга мөмкин. Мондый хәлләр татар журналистикасында бик киң таралган, һәм теләсә кайсы татар журналисты үзе ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән яки ярдәм күрсәткән очракларны исенә төшерә ала торгандыр. Андый ярдәмчеллек рухын үзара көндәшлек рухында яшәгән Мәскәү басмалары арасында күз алдына да китерүе кыен. Башка массакүләм мәгълүмат чарасына мәгълүмат бирүне ул җәмгыятьтә, аларның һөнәри кодексларында хәтта хыянәт дип атарга да мөмкиннәр әле. Ул җәмгыятьтә бу адым шулай дип күренә дә.

Бер караганда, татар журналистикасына хас дип атаган әлеге этик нормаларның кайберләре совет чоры журналистикасының этик нормалары белән тәңгәл килә иде, шуңа да моңарчы барлык СССР журналистлары белән беррәттән татар журналистлары тарафыннан да үтәлеп киленде. Шуңа күрә ул чакта татар журналистикасының һөнәри этика нормаларының татар җәмгыяте кагыйдәләре белән артык каршылыкка керүе күзәтелмәде дә. Әмма бүгенге көндә ул каршылык күзгә артык ташлана инде.

## Россия журналистының һөнәри этика кодексы

1. Журналист һәрвакытта да кабул итүе, хуплавы һәм үтәве Россия Журналистлар берлегендә әгъза булып торуның төп таләбе булган әлеге Кодекста теркәлгән һөнәри этика принципларыннан чыгып эш итәргә тиеш.

2. Журналист үз иленең законнарын үти, әмма һөнәри бурычын башкаруга килгәндә, бары тик үз коллегалары юрисдикциясен генә таный, хакимият яки кем-нәрсә булуына карамастан, башка якларның басым ясау һәм катышуын кире кага.

3. Журналист дөреслегенә ышанган һәм чыганагы аңа яхшы таныш булган мәгълүматны гына тарата һәм комментарий бирә. Ул җәмәгатьчелек өчен әһәмиятле мәгълүматның тулы булмавы яки төгәлсезлеге, күрәләтә яшереп калдыру яки ялган мәгълүмат тарату аркасында кемгә дә булса зыян салудан котылыр өчен барлык көчен куя.

Журналист үз хәбәрләрендә үзе сөйли торган фактлар һәм фикер, версия яки фаразлауларны тәшкил иткән мәгъдүматны катгый аерып куярга тиеш, шул

ук вакытта аннан һөнәри эшчәнлегендә нейтраль мөнәсәбәттә булу таләп ителми.

Һөнәри вазыйфаларын үтәү барышында журналист мәгълүмат алуның законсыз һәм түбән ысулларына мөрәҗәгать итми. Журналист физик һәм юридик затларның, әгәр бу закон белән мәҗбүриләнмәгән икән, мәгълүмат бирмәү һәм сорауларга җавап бирмәү хокукы барлыгын хөрмәт итә.

Журналист фактларны усал рәвештә үзгәртеп күрсәтү, нахак бәла ягу, ялган мәгълүматны тараткан яки дөресен яшереп калдырган өчен түләү алу очракларын авыр һөнәри җинаять итеп кабул итә; журналист гомумән дә турыдан-туры да, читләтеп тә материаллар яки төрле характердагы фикерләрен бастырган өчен өченче затлардан бернинди дә бүләк яки гонорар алырга тиеш түгел.

Ялган яки бозылган материал бастыруын аңлап алганнан соң, журналист, материалны бастыруда кулланылган шул ук полиграфик яки аудиовизуаль чараларны файдаланып, үзенең хатасын төзәтергә тиеш.

Журналист аның имзасы, псевдонимы астында яки аноним рәвештә тараткан һәр хәбәренең дөреслеге һәм фикерләренең хаклыгы өчен үзенең исеме һәм репутациясе белән җавап бирә. Аның теләгенә каршы килеп үзгәртелгән хәбәр яки фикер астыннан үз имзасын алып атуны аңа беркем дә тыя алмый.

4. Журналист конфиденциаль юл белән алынган мәгълүматның чыганагына карата һөнәри серне саклый. Бу чыганакның кем икәнен ачарга аны беркем дә мәҗбүр итә алмый. Аноним булу хокукы бары тик чыганак белә торып дөреслекне бозган дигән шик булганда, шулай ук чыганакның исемен атау кешеләр өстенә килерлек авыр һәм туктатып калып булмаслык зыяннан котылу булган санаулы очракларда гына бозыла ала.

Журналист интервью бирүчеләрнең аларның фикерен рәсми рәвештә чыгармауларын сораган үтенечләрен хөрмәт итәргә бурычлы.

5. Журналист эшчәнлеге нәтиҗәсендә килеп чыгарга мөмкин булган аны чикләү, эзәрлекләү һәм көч куллану куркынычы булуын тулысынча аңлый. Үзенең һөнәри вазыйфасын үтәү барышында, ул экстремизм һәм гражданлык хокукларын төрле сыйфатлар, мәсәлән, җенес, раса, тел, дин, сәяси һәм башка карашлар, шулай ук социаль һәм милли килеп чыгыш аркасында кысрыклауга каршы тора.

Журналист һөнәри игътибарына алына торган кешеләрнең намусы һәм дәрәҗәсен хөрмәт итә. Кешенең расасы, милләте, тән төсе, дине, социаль килеп

чыгышы яки җенесенә, шулай ук физик җитешсезлеге яки чиренә карата әдәпсез сүз яки комментарийлардан тыела. Әгәр алар бастырыла торган хәбәрнең төп эчтәлеген тәшки итмәсә, бу мәгълүматларны халыкка таратудан тыела. Журналист кешеләрнең әхлакый һәм физик сәламәтлегенә зыян салырлык кимсетерлек сүзләрдән берсүзсез баш тарта.

Журналист теләсә кайсы кеше суд тарафыннан капма-каршысы расланганга кадәр гаепсез санала дигән принципка тугъры кала. Үзенең хәбәрләрендә, проблеманы объектив яктырту өчен таләп ителмәгән очракларда, җинаятьтә гаепле дип табылган яки шуның өчен җәза үтәүчеләрнең туганнары һәм дусларының исемнәрен атамый. Ул шулай ук җинаять корбанының исемен атаудан һәм ул корбанның шәхесен ачыкларга ярдәм итәрлек материалларны бастырудан тыела. Журналист хәбәре балигъ булмаганнарга кагылырга мөмкин булганда, бу таләпләр аеруча катгый үтәлә.

Бары тик җәмгыять ихтыяҗын яклау гына кешенең шәхси тормышына үтеп керергә омтылган журналист тикшерүен аклый ала. Әгәр сүз медицина яки шуның кебек оешмаларга урнаштырылган кешеләр турында бара икән, мондый чикләүләр берсүзсез үтәлә.

6. Журналист һөнәри статусын дәүләт идарә органнарында эшләү, шулай ук сәяси партияләр яки сәяси юнәлештәге башка оешмаларда җитәкче органнарда тору белән яраштыра алмый.

Журналист кулына корал алу белән һөнәри эшчәнлеге тукталуын аңлый.

7. Журналист үзенең репутациясе, авторитеты, шулай ук һөнәри хокуклары һәм мөмкинлекләрен реклама характерындагы (яки реклама икәнлеге аермачык күренеп тормаган) материаллар таратуда файдалануны үзе өчен түбәнлек итеп кабул итә. Журналистлык һәм реклама эшчәнлегенең үзара ярашуы гомумән дә этик яктан кабул ителми.

Журналист һөнәренә бәйле рәвештә ирешкән конфиденциаль мәгълүматны шәхси яки якын кешеләренең ихтыяҗларында файдалана алмый.

8. Журналист хезмәттәшләренең һөнәри хокукларын хөрмәт итә һәм яклый. Журналист, аларның вазыйфаларын социаль, матди һәм әхлакый планда начаррак шартларда да үтәргә ризалашып, коллегаларының шәхси яки һөнәри ихтыяҗларына зыян салырлык стиуацияләрне булдырмаска тырыша.

Журналист теләсә кайсы иҗади эшчәнлеккә бәйле авторлык хокукларын хөрмәт итә һәм башкаларны да хөрмәт иттерә. Плагиат рөхсәт ителми. Нинди дә булса ысул белән коллегасының хезмәтен кулланса, журналист аны аермачык күрсәтә.

9. Әгәр аны үтәү югарыда аталган принципларны бозу белән бәйле булса, журналист биремнән баш тарта.

10. Журналист көчләүгә яки көчләү, мыскыл итү, әхлакый зыян, диффамациягә белән янауга каршы торганда, гражданлык җинаять җаваплылыгына бәйле законнар белән урнашытырылган суд яки башка тәртиптәге яклау гарантияләреннән файдалана һәм файдалану мөмкинлекләре өчен көрәшә.

**Кодекс Россия журналистлары конгрессы тарафыннан**
**1994 елның 23 июнендә кабул ителгән. Мәскәү.**